ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1802**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 декабрендәге 3361 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы "Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 06 апрелендәге 608 номерлы "Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында"гы карары, Татарстан Республикасы "Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 декабрендәге 3361 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5.1 пунктындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина күпфатирлы йорт дип таныла».

2. Зеленодольск муниципаль районы Совет Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев